| МИНИСТЕРСТВ ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МОНОСЭБОТЛЭРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

05.07.2023 Казан ш. № 1850-р

Бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (өлешчә) территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 15.12.2014 № 2881-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм «БАРС» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе хатын исәпкә алып (02.03.2023 № 01А-04/409) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милке булган, Питрәч муниципаль районы Богородское авылы территориясендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (өлешчә) территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 15.12.2014 № 2881-р карары (алга таба - №2881-р карар) белән урнаштырылган 25 861 инвентарь номерлы 2281 м озынлыктагы һәм 37 758 инвентарь номерлы 525 м озынлыктагы, учет номеры 16.33.2.511 булган бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын, 16:33:050301:348, 16:33:050301 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә түбән басымлы газүткәргеч кишәрлекләренең үзгәртелүе сәбәпле, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, «БАРС» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп үзгәртергә. Инвентарь номерлары 25861 һәм 37758 булган бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасы озынлыгы (11152 ± 37) кв.м.лы гомуми мәйдан территориясендә 2283,04 һәм 525 м.ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номерлары 25 861 һәм 37 758 булган газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында өлешчә яки тулысынча газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «БАРС» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасына, газүткәргечнең характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, № 2881-р Карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 21.07.2017 № 1709-р, 15.10.2018 № 3420-р, 29.04.2021 № 1386-р, 26.10.2021 № 3261-р Карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада:

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карары” сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта 1.1 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Питрәч муниципаль районы территориясендә урнашкан 375,5995 км озынлыктагы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Приволжскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Граница» кадастр үзәге” ҖЧҖ, «Земля» РКЦ АҖ, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ, «Гео-Инженеринг» ҖЧҖ, «БАРС» ҖЧҖ тарафыннан башкарылган җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зоналары картасына (планында) булган мәгълүматлар буенча;

1 нче кушымтада 98 юлны әлеге карарның кушымтасы редакциясендә бәян итәргә (бастырып чыгару каралмаган).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**